# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге составына керүче Горка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 ноябрь 2019 ел. № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 13 ноябрендә «2020 елда Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- урам утларын карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 107 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 55 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 55 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге составына керүче Горка авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.
2. “2020 елда Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче Төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- урам утларын карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;

- янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Горка авылы, Ленин урамы, 2а санлы йорт адресындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майна авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Гафиятуллин